Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

14 нче июнь 2017 ел

№8

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына (кушымта) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 ст. 1, 2 п. п. һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 16 ст. 1 ө. 20 п. һәм «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, авыл җирлеге территориясендә җирдән рациональ файдалану максатларында җир законнарын бозуларны бетерү турында прокуратура 2016 елның 25 мартындагы 02-02-02/2016 номерлы күрсәтмәсен карап, Әлмәт авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының 18.03.2013 ел, № 5 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына (кушымта) үзгәрешләр кертергә.

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе

Д.Ә. Газизов.